СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025ел 14 феврале г.Мензелинск № 4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының «Минзәлә муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» 10.12.2021 ел № 4 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»31.07.2020 № 248-ФЗ Федераль законы,«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»28.12.2024 № 540-ФЗ Федераль законы,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә
КАРАР ЧЫГАРА:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының «Минзәлә муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында»10.12.2021 ел № 4 карарына түбәндәге үзгәрешләркертергә:

1.1 «Минзәлә муниципаль контроле территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәләр» нең 20 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үткәрелә торган контроль чаралар кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган, актлар рәсмиләштерелгән һәм (яисә) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелгән очракта, күрсәтелгән актлар һәм (яисә) күрсәтмәләр контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында исәпкә алынырга тиеш»;

1.2. 29 пунктта «ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә» сүзләреннән соң «мәҗбүри таләпләр» сүзләрен, «һәм (яки) закон белән саклана торган кыймматләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы Басков Евгений Алексеевичка йөкләргә.

Совет рәисе А. Ф. Сәлахов